РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.08.2017 № 162-п

*Хезмәт күрсәтү предприятиеләре коллективларының 2016 елгы эш нәтиҗәләре турында*

Хезмәт күрсәтү предприятиеләре коллективларының 2016 елгы эш нәтиҗәләрен караганнан соң,

КАРАР БИРӘМ:

1. Табыш белән эшләп, район халкына һәм оешмаларга 59 млн. 811 мең сумлык җылылык, су белән тәэмин итү, санитар чистарту, мунча, кунакханә хезмәтләре күрсәткән "Торак-коммуналь хуҗалыгының Саба күптармаклы җитештерү предприятиесе" акционерлык җәмгыятенә (җитәкчесе Хәбибуллин И.Г.) беренче урын бирергә һәм коллективны беренче дәрәҗәдәге Диплом белән бүләкләргә.

Җитәкчегә акчалата бүләк тапшырырга һәм аеруча яхшы эшләүчеләрне бүләкләү өчен 10 мең сум күләмендә премия бүләргә.

2. 60 млн. 142 мең сум күләмендә транспорт хезмәте күрсәткән, барлык салымнарны вакытында түләүне тәэмин иткән җаваплылыгы чикләнгән "Яшен" җәмгыятенә (җитәкчесе Зарипов Р.С.),

табыш белән эшләп, район халкына һәм оешмаларга 53 млн. 539 мең сумлык җылылык, су белән тәэмин итү, санитар чистарту, мунча, кунакханә хезмәтләре күрсәткән "Торак-коммуналь хуҗалыгының Шәмәрдән күптармаклы җитештерү предприятиесе" ачык акционерлык җәмгыятенә (җитәкчесе Тимергалиев Н.Н.) икенче урын бирергә һәм коллективларны икенче дәрәҗәдәге Диплом белән бүләкләргә.

Җитәкчеләргә акчалата бүләк тапшырырга һәм аеруча яхшы эшләүчеләрне бүләкләү өчен 8әр мең сум күләмендә премия бүләргә.

3. 119 млн. 441 мең сум күләмендә электр элемтәсе хезмәте күрсәткән, рентабельле эшләүгә, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга ирешкән "Таттелеком" ачык акционерлык җәмгыятенең Саба электр элемтәсе узелына (җитәкчесе Галиев А.Т.) өченче урын бирергә һәм коллективны өченче дәрәҗәдәге Диплом белән бүләкләргә.

Җитәкчегә акчалата бүләк тапшырырга һәм аеруча яхшы эшләүчеләрне бүләкләү өчен 6 мең сум күләмендә премия бүләргә.

Р.Н. Минниханов